**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

26.12.2023 № 406

**Татарстан Республикасы Президентының «Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында» 2015 елның 24 июнендәге 389 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 26 августындагы 502 номерлы һәм 2022 елның 21 сентябрендәге 304 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «(дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләре»)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 26 » декабрендәге
406 номерлы боерыгына
кушымта

**Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе билгеләнә.

2. Әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган максатлар өчен түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алынган бүләк – бүләк бирелә торган затның вазыйфа биләвеннән яисә аның вазыйфа башкаруыннан чыгып бүләк тапшыра торган физик (юридик) затлардан, протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар вакытында әлеге чараларда катнашучы һәркемгә аларга хезмәт вазыйфаларын башкару максатларында тапшырылган канцелярия кирәк-яракларыннан, чәчәкләрдән һәм бүләкләү буларак тапшырылган кыйммәтле әйберләрдән тыш, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алынган бүләк;

вазыйфа биләве белән бәйле яисә хезмәт вазыйфалары башкаруы белән бәйле бүләк алу – Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан шәхсән яисә арадашчы аша физик (юридик) затлардан Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләрен башкарганда, шулай ук аның законнарда билгеләнгән хезмәт вазыйфаларын башкаруы белән бәйле бүләк алу.

3. Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алынган бүләк (алга таба – бүләк) аны алган көннән өч эш көненнән дә соңга

калмыйча кабул итү-тапшыру акты нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла.

Әгәр бүләк хезмәт командировкасы вакытында алынган булса, ул Татарстан Республикасы Рәисе хезмәт командировкасыннан кайтканнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

4. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы Рәисенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында бүләкне тапшыру мөмкин булмаган очракта, бүләк әлеге сәбәпләр бетерелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Татарстан Республикасы Рәисе бүләк алу очракларының барысы турында да Россия Федерациясе Президентының «Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затларның, Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затларының үзләренең бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру, бәясен билгеләү һәм аны сату (түләп алу) турында» 2015 елның 29 маендагы 159-рп номерлы боерыгында (алга таба – Россия Федерациясе Президенты боерыгы) каралган тәртиптә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенә хәбәр итә.

6. Бүләк алу турындагы хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ике нөсхәдә Россия Федерациясе Президенты боерыгына 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча әзерләнә һәм Россия Федерациясе Президентының Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре идарәсенә әлеге Нигезләмәнең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән срокларда тапшырыла. Хәбәрнамәгә бүләкнең бәясен раслаучы документлар (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен акча түләнгәнне белдергән башка документ) (булган очракта) теркәлә.

Хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Рәисенә кул куяр өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе әзерли. Әгәр дә Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе рәсми чараны уздыруда катнашмаса, мондый әзерлекне Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең рәсми чараны уздыру өчен җаваплы структур бүлекчәсе (вазыйфаи заты) башкара.

7. Бүләк алу турындагы хәбәрнамәнең беренче нөсхәсе, аны Россия Федерациясе Президентының Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре идарәсе теркәгәннән һәм аның белән Россия Федерациясе Президенты Администрациясе Җитәкчесе танышканнан соң, Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенә кире кайтарыла. Бүләк алу турындагы хәбәрнамәнең икенче нөсхәсе Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрелә.

8. Бүләкне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының җаваплы затына саклауга тапшыру Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе һәм Татарстан

Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе тарафыннан тәэмин ителә. Әгәр дә Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе рәсми чараны уздыруда катнашмаса, мондый тапшыру Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең рәсми чараны уздыру өчен җаваплы структур бүлекчәсе (вазыйфаи заты) тарафыннан башкарыла.

9. Бүләкне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык хисабына алу максатларында аның бәясен билгеләү бүләкне хисапка алу датасына гамәлдә булган базар бәясе яисә охшаш шартлардагы шундый ук кыйммәтле әйбернең бәясе нигезендә, кирәк булганда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы активлары керү һәм чыгу буенча бухгалтерлык хисабына алу турындагы законнар нигезендә төзелгән комиссияне (алга таба – комиссия) җәлеп итеп башкарыла. Базар бәясе турындагы белешмәләр документларга нигезләнеп, ә документларга нигезләнеп раслау мөмкин булмаганда, экспертиза уздыру юлы белән раслана. Бүләкнең бәясе өч мең сумнан артмаса, ул Татарстан Республикасы Рәисенә кабул итү-тапшыру акты буенча кайтарыла.

10. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы бәясе өч мең сумнан арткан, бухгалтерлык хисабына алынган бүләкне билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертүне тәэмин итә.

11. Татарстан Республикасы Рәисе үзе тапшырган бүләкне Россия Федерациясе Президентының Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре идарәсенә бүләкне тапшырган көннән башлап ике айдан да соңга калмыйча Россия Федерациясе Президенты боерыгына 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча бүләкне сатып алу турында ике нөсхәдә язылган гариза биреп сатып алырга мөмкин. Бүләкне сатып алу турындагы гаризаны Татарстан Республикасы Рәисенә кул кую өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе әзерли.

Бүләкне сатып алу турындагы гариза бүләк алу турындагы хәбәрнамә белән бер үк вакытта бирелергә мөмкин. Бу очракта аны кул куюга әзерләү әлеге Нигезләмәнең 6 пунктындагы икенче абзацта күрсәтелгән затлар тарафыннан башкарыла.

12. Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә гаризаның беренче нөсхәсе аның белән Россия Федерациясе Президенты Администрациясе Җитәкчесе танышканнан соң Татарстан Республикасы Рәисенә тапшырыла. Гаризаның икенче нөсхәсе бүләкнең бәясен билгеләү һәм аны сату (түләп алу) максатларында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрелә.

13. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән гариза кергән көннән башлап өч ай дәвамында сату (түләп алу) өчен бүләкнең бәясен билгеләүне оештыра һәм бәяләү нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Рәисенә язма рәвештә хәбәрнамә бирә, моннан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Рәисе бәяләү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән бәягә бүләкне сатып ала яисә сатып алудан баш тарта.

14. Аңа карата әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән гариза кермәгән бүләк, кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләктән тыш, комиссиянең Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүләкне файдалануның максатка ярашлыгы турында нәтиҗәсен исәпкә алып кабул ителгән Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе карары буенча билгеләнгән тәртиптә тиешле экспозиция формалаштыру максатларында файдалану өчен «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшырыла.

15. Кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләкне сатып алу турында гариза бирелмәгән очракта, мондый бүләк Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондына бирү өчен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы Россия Федерациясенең кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм асылташларны саклау, тапшыру һәм файдалану буенча дәүләт учреждениесе (Россия Гохран)» федераль казна учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

16. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан бүләкне тапшырган көннән алты ай дәвамында әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында каралган карар кабул ителмәгән очракта Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры тарафыннан бүләкне сату һәм аны сату (түләп алу) өчен Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә сәүдә уздыру юлы белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан аның бәясен билгеләүне уздыру турында карар кабул ителә.

Бүләкне файдалану максатка яраклы булмаганда, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе

17. Бүләкне сату (түләп алу) өчен әлеге Нигезләмәнең 13 һәм 16 пунктларында каралганча аның бәясен билгеләү бәяләү эшчәнлеге субъектлары тарафыннан Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында законнары нигезендә башкарыла.

18. Әгәр бүләк түләп алынмаса яисә сатылмаса, Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры тарафыннан аны кабаттан сату турында яисә аны хәйрия оешмасы балансына түләүсез тапшыру яки Россия Федерациясе законнары нигезендә аны юкка чыгару турында карар кабул ителә.

19. Бүләкне сатудан (түләп алудан) кергән акча Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына керем буларак хисаплана.

20. Әлеге Нигезләмәгә таянып җайга салып булмый торган мәсьәләләрне хәл иткәндә, Россия Федерациясе Президенты боерыгына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган Аерым категориядәге затларның үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк

алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү турында типовой нигезләмәгә таянырга.